**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**“05” апрель 2024 ел, № 2**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Гарталовка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Гарталовка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Гарталовка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 13 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Гарталовка авылында гражданнар җыенының 2024 елның 05 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре яңа редакция белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 26 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 14 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халiык җыенында катнашкан 14 кеше

тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында халык җыены булып узган, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Халык җыены нәтиҗәләре соравын яңа редакциядә кабул итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Арча районы, Гарталовка авылы, Урман урамы, 5 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan. ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков